КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 28 март г.Казань № 199

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәдәният, сәнгать, кинематография, анимация, мәдәни мирасны популярлаштыру, дәүләт милли сәясәте, халыкара, төбәкара хезмәттәшлек өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга, чаралар оештыруга һәм уздыруга, Россия Федерациясендә һәм дөньякүләм киңлектә татар мәдәниятен популярлаштыруга, сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган Татарстан АССРда туучыларны һәм анда яшәүчеләрне эзләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 16 август, 732 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 16 декабрь, 1240 нчы; 2022 ел, 15 июль, 678 нче; 2023 ел, 1 март, 193 нче; 2023 ел, 4 октябрь, 1229 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Мәдәният, сәнгать, кинематография, анимация, мәдәни мирасны популярлаштыру, дәүләт милли сәясәте, халыкара, төбәкара хезмәттәшлек өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыруга, чаралар оештыруга һәм уздыруга, Россия Федерациясендә һәм дөньякүләм киңлектә татар мәдәниятен популярлаштыруга, сугыш елларында хәбәрсез югалган дип саналган Татарстан АССРда туучыларны һәм анда яшәүчеләрне эзләү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) коммерцияле булмаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның беренче абзацында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалкан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары,» сүзләрен төшереп калдырырга;

10 пунктның уналтынчы абзацына «(булганда)» сүзен өстәргә;

әлеге Тәртипнең кушымтасында «М.У.» аббревиатурасыннан соң «(булганда)» сүзен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт театрларына һәм концерт оешмаларына «Академик» исеме бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2021 ел, 9 октябрь, 962 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт театрларына һәм концерт оешмаларына «Академик» исеме бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә, 2.3 пунктның беренче абзацына «мөһер» сүзеннән соң «(булганда)» сүзен өстәп, үзгәреш кертергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Милли үзенчәлекне саклау, милли (туган) телне һәм милли мәдәниятне үстерү, төбәкара хезмәттәшлекне ныгыту һәм үстерү өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга матди-техник базаны ныгытуга һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның иҗат коллективларының матди-техник базасын ныгытуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 30 декабрь, 1341 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 13 август, 807 нче; 2023 ел, 1 март, 193 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Милли үзенчәлекне саклау, милли (туган) телне һәм милли мәдәниятне үстерү, төбәкара хезмәттәшлекне ныгыту һәм үстерү өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга матди-техник базаны ныгытуга һәм Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыкларның иҗат коллективларының матди-техник базасын ныгытуга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалкан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары,» сүзләрен төшереп калдырырга;

10 пунктның унөченче абзацына «(булганда)» сүзен өстәргә;

әлеге Тәртипнең кушымтасында «М.У.» аббревиатурасыннан соң «(булганда)» сүзен өстәргә.

2. Бу карар (әлеге карарның 2024 елның 1 июненнән үз көченә керә торган 1 пунктының өченче һәм дүртенче абзацларыннан, 2 пунктыннан, 3 пунктның өченче һәм дүртенче абзацларыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин